КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 декабрь г.Казань № 1044

2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләрен раслау турында

Россия Федерациясе гражданнарының медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүгә конституция хокукларын тәэмин итү максатларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы турында» 2016 ел, 19 декабрь, 1403 нче карарын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2017 елда Программа кысаларында медицина хезмәтләре күрсәтүгә исәп-хисапларны тәмамлау 2018 елның 15 февраленә кадәр тәмамлау;

Программаны тормышка ашыруда катнашучы медицина оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм «Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә законнар нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм формаларда мәҗбүри медицина иминияте тармагында эшчәнлек турында хисап һәм Программа расланган көннән соң 14 көн эчендә тиешле финанс елына финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнары тапшырыла;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләр буенча вәкаләтләр йөкләнә:

Татарстан Республикасында мәҗбүри медицина иминиятенең территориаль программасы буенча медицина ярдәменә түләү турында тариф килешүе төзү;

беренче чиратта бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру өчен медицина оешмалары тарафыннан мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина ярдәме өчен түләү тарифлары һәм тәртибен эшләү һәм раслау өчен вәкаләтле органга тапшыру;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып рәсми сайтта Программаны һәм медицина ярдәменә түләү өчен билгеләнгән тарифларны урнаштыру;

2017 елның 15 февраленә кадәр медицина оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлегенең килештерелгән планнарын «Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды» дәүләт учреждениесенә тапшыруны тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына һәм Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондына «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы һәм «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына Татарстан Республикасы мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 94-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнарында әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында Программаны тормышка ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

4. Бу карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин